КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 июнь г.Казань № 483

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 12 июль, 567 нче; 2019 ел, 8 ноябрь, 1023 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1279 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа:

Программа исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«Программаның дәүләт заказчылары» юлында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программалар исемлеге | 1. «2019 – 2023 елларга физик культура һәм массакүләм спортны үстерү».<br>2. «2019 – 2023 елларга бгары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү».<br>3. «2019 – 2023 елларга физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү».<br>4. «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | 2019 – 2023 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 33 198 417,5 мең сум тәшкил итә, шулардан:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 30 576 471,3 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда –4 417 725,9 мең сум;<br>2020 елда – 7 540 922,1 мең сум;<br>2021 елда – 7 484 448,3 мең сум;<br>2022 елда – 5 566 687,5 мең сум;<br>2023 елда – 5 566 687,5 мең сум;<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән –2 359 735,3 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 401 646,7 мең сум;<br>2020 елда – 1 319 531,6 мең сум;<br>2021 елда – 329 333,5 мең сум;<br>2022 елда – 265 201,3 мең сум;<br>2023 елда – 44 022,2 мең сум;<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 345 200,0 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 0,0 мең сум;<br>2020 елда – 345 200,0 мең сум;<br>2021 елда – 0,0 мең сум;<br>2022 елда – 0,0 мең сум;<br>2023 елда – 0,0 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле финанс елына бюджет проектын формалаштыр-ганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш |

| | |
|---|---|
| | чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тормышка ашыру 2023 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>халыкның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче халык өлешен 54,5 процентка кадәр;<br>«Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын бирүдә катнашкан халыкның гомуми санында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәгән Татарстан Республикасы халкы өлешен 57,0 процентка кадәр;<br>сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче бу категориядәге халык өлешен 29,0 процентка кадәр;<br>физик культура һәм спорт өлкәсендәге оешмаларның гомуми санында федераль спорт әзерлеге стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча хезмәт күрсәтүче (шул исәптән физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен) оешмалар өлешен 100 процентка кадәр;<br>спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт буенча камилләшү этабында шөгыльләнүчеләрнең гомуми санында спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда югары спорт осталыгы этабында шөгыльләнүчеләр өлешен 25,0 процентка кадәр;<br>Россия Федерациясенең спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлегенә кертелгән спортчылар санын 577 кешегә кадәр;<br>спорт билгеләнешендәге объектларның берьюлы хезмәт күрсәтү сәләтеннән чыгып, гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен 67,9 процентка кадәр;<br>100 мең кешегә исәпләгән спорт корылмалары санын 310 берәмлеккә кадәр;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен электр энергиясенең чагыштырма чыгымы (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – 1 кв.метрга 65,67 кВт × сәгать; |

| | |
|---|---|
| | спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен җылылык энергиясенең чагыштырма чыгымы (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга 0,1340 Гкал;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен салкын суның чагыштырма чыгымы (1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) исәпләгәндә) – 1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) 0,1762 куб.метр;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен табигый газның чагыштырма чыгымы (газ белән җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә) – газ белән җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына 29,49 куб.метр;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының ведомство буйсынуындагы мәҗбүри энергетика тикшерүен үткән учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча) өлешен 100 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының ведомство буйсынуындагы исәпкә алу приборлары белән җиһазландырылган учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча) өлешен 100 процентка кадәр»; |

Программаның I бүлегендә:

кырык сигезенче абзацта «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

кырык тугызынчы абзацта «2022» һәм «51,4» саннарын тиешенчә «2023» һәм «54,5» саннарына алмаштырырга;

Программаның II – III бүлекләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Программаның төп максаты һәм бурычлары, программа чаралары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирнамәсе, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Программаның максаты булып Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру тора.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Татарстан Республикасы халкының физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивациясен арттыру.

2. Спорт резервын әзерләү системасын камилләштерү һәм Татарстан Республикасы спортчыларының төбәкара, бөтенроссия ярышларында һәм Россия Федерациясе җыелма командалары составында иң эре халыкара спорт ярышларында уңышлы чыгыш ясавын тәэмин итү.

3. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәте нәтиҗәлелеген күтәрү.

4. Спорт һәм инженерлык инфраструктурасын ныгыту, шулай ук спорт корылмаларының энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү.

Куелган максатның масштаблылыгы чаралар комплексын эшләүне таләп итә.

Физик культура һәм массакүләм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, Татарстанның спорт имиджын ныгыту өчен «2019 – 2023 елларга физик культура һәм массакүләм спортны үстерү» ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программа сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, барлык яшьтәге халык төркемнәренең физик активлыгын һәм әзерлеген арттыруга, тулы кыйммәтле итеп ял итү һәм буш вакытны сәламәт итеп үткәрү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны башкаруны күздә тота.

Әлеге чараларны тормышка ашыру Татарстан Республикасы халкының сәламәтлеген ныгыту өчен шартлар тудырырга, республикада демографик хәлне яхшыртырга, массакүләм спортны үстерергә һәм популярлаштырырга, алга таба Татарстанның спорт имиджын халыкара дәрәҗәдә ныгыту максатларында, җәмгыятьнең төрле катламнарын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2023 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

халыкның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче халык өлешен 54,5 процентка кадәр;

«Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын бирүдә катнашкан халыкның гомуми санында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәгән Татарстан Республикасы халкы өлешен 57,0 процентка кадәр;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче бу категориядәге халык өлешен 29,0 процентка кадәр.

Спорт резервын әзерләүне һәм Татарстан Республикасы спортчыларының Россия һәм халыкара спорт ярышларында уңышлы чыгыш ясавын тәэмин итү максатларында «2019 – 2023 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү» ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программа спорт резервын әзерләүгә, спорт мәктәпләре укучыларының спорт нәтиҗәләрен камилләштерүгә, физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне фәнни, аналитик һәм методик яктан тәэмин итү системасына ярдәм итүгә, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына һәм спорт юнәлешендәге һөнәри белем бирү оешмаларына ярдәм күрсәтүгә, югары казанышлар спортын (профессиональ спортны) үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үтәүне күздә тота.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2023 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

Россия Федерациясенең спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлегенә кертелгән спортчылар санын 577 кешегә кадәр;

физик культура һәм спорт өлкәсендәге оешмаларның гомуми санында федераль спорт әзерлеге стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча хезмәт күрсәтүче (шул

исәптән физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен) оешмалар өлешен 100 процентка кадәр;

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт буенча камилләшү этабында шөгыльләнүчеләрнең гомуми санында спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда югары спорт осталыгы этабында шөгыльләнүчеләр өлешен 25 процентка кадәр;

Татарстан Республикасы халкының сәламәтлеген ныгыту, республикада демографик хәлне ныгыту, массакүләм спортны һәм югары казанышлар спортын (профессиональ спортны) үстерү һәм популярлаштыру, җәмгыятьнең төрле катламнарын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү, халыкара дәрәҗәдә Татарстанның спорт имиджын ныгыту, күзәтүсезлекне, экстремизмны, хокук бозуларны, тәмәке тартуны, алкоголизмны, наркоманияне һәм башка тискәре социаль күренешләрне профилактикалау, шулай ук ягулык-энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану өчен шартлар тудыру максатларында, «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру күздә тотыла.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге түбәндәге индикаторлар белән бәяләнә:

100 мең кешегә спорт корылмалары саны, берәмлек;

спорт билгеләнешендәге объектларның берьюлы хезмәт күрсәтү сәләте, процент;

спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен электр энергиясенең чагыштырма чыгымы (1 кв.метр гомуми мәйданга исәпләгәндә), 1 кв.метрга кВт × сәгать;

спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен җылылык энергиясенең чагыштырма чыгымы (җылылык энергиясе белән җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә), җылылык энергиясе белән җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга Гкал;

спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен салкын суның чагыштырма чыгымы (1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) исәпләгәндә), 1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) куб метр;

спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен табигый газның чагыштырма чыгымы (газ белән җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – газ белән җылытыла торган 1 кв. метр мәйданга куб.метр;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының ведомство буйсынуындагы мәҗбүри энергетика тикшерүен үткән учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча) өлеше, процент;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының ведомство буйсынуындагы исәпкә алу приборлары белән җиһазландырылган учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча) өлеше, процент.

Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чаралары буенча финанслау аңа теркәлгән кушымтада китерелә.

Программаны тормышка ашыруның гомуми вакыты: 2019 – 2023 еллар.

## III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2023 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 33 198 417,5 мең сум тәшкил итә, шулардан:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 30 576 471,3 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 4 417 725,9 мең сум;

2020 елда – 7 540 922,1 мең сум;

2021 елда – 7 484 448,3 мең сум;

2022 елда – 5 566 687,5 мең сум;

2023 елда – 5 566 687,5 мең сум

җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 2 359 735,3 1 753 498,21 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 401 646,7 мең сум;

2020 елда – 1 319 531,6 мең сум;

2021 елда – 329 333,50 мең сум;

2022 елда – 265 201,30 мең сум;

2023 елда – 44 022,20 мең сум

җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 345 200,0 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 0,0 мең сум;

2020 елда – 345 200,0 мең сум;

2021 елда – 0,0 мең сум;

2022 елда – 0,0 мең сум;

2023 елда – 0,0 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

«2019 – 2021 елларга физик культура һәм массакүләм спортны үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

1 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«1 нче ярдәмче программада катнашучылар» юлында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

«1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 156 651,4 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 973 896,6 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 318 916,6 мең сум;<br>2020 елда – 163 745,0 мең сум;<br>2021 елда – 163 745,0 мең сум;<br>2022 елда – 163 745,0 мең сум;<br>2023 елда – 163 745,0 мең сум.<br>Федераль бюджет акчасы исәбеннән күздә тотылган финанслау 182 754,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2019 елда – 69 341,1 мең сум;<br>2020 елда – 48 299,0 мең сум;<br>2021 елда – 14 997,3 мең сум;<br>2022 елда – 25 058,7 мең сум;<br>2023 елда – 25 058,7 мең сум.<br>1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«1 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «1 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 1 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә 2023 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>халыкның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче Татарстан Республикасы халкы өлешен 54,5 процентка кадәр;<br>«Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын бирүдә катнашкан халыкның гомуми санында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәгән Татарстан Республикасы халкы өлешен 57,0 процентка кадәр: |

| | |
|---|---|
| | шулардан укучыларның һәм студентларның өлешен 65,0 процентка кадәр;<br>сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче бу категориядәге халык өлешен 29,0 процентка кадәр;<br>6 яшьтән 18 яшькә кадәр сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче бу категориядәге халык өлешен 75,0 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы халкының гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче авыл халкы өлешен 34,6 процентка кадәр;<br>3 – 29 яшь категориясендәге балалар һәм яшьләрнең гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр өлешен 88,0 процентка кадәр;<br>урта яшьтәге гражданнарның (30 – 54 яшьтәге хатын-кызлар өчен һәм 30 – 59 яшьтәге ир-атлар өчен) гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче урта яшьтәге гражданнар өлешен 48,6 процентка кадәр;<br>өлкән яшьтәге гражданнарның (55 яшь һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге хатын-кызлар өчен һәм 60 яшь һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ир-атлар өчен) гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче өлкән яшьтәге гражданнар өлешен 24,7 процентка кадәр»; |

1 нче ярдәмче программаның II – III бүлекләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Дәүләт сәясәтенең приоритетлары һәм максатлары, 1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы

Әлеге 1 нче ярдәмче программа Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А.Медведев тарафыннан расланган 2018 елның 29 сентябрендәге 8028-П13 номерлы 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең 2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе Хөкүмәте эшчәнлегенең төп юнәлешләрен, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 29 март, 363 нче карарын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 ел, 7 август, 1101-б номерлы боерыгын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Физик культура һәм спортны үстерү»

Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 15 апрель, 302 нче карарын, "Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карарын, «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан эшләнгән 2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль тармакларны һәм иҗтимагый инфраструктураны үстерү концепциясен исәпкә алып эшләнгән.

Физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатлары регионның социаль-икътисадый үсешенең чын шартлары белән билгеләнгән, ул Татарстан Республикасы гражданнары тарафыннан сәламәт яшәү рәвешен алып бару, аларны физик культура һәм массакүләм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен кирәкле шартлар булдыруны күздә тота.

Күрсәтелгән программа документлары түбәндәге өстенлекле юнәлешләрне ассызыклый:

Татарстан Республикасы халкының төрле яшь категорияләрен һәм төркемнәрен физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү;

Татарстан Республикасы халкының физик әзерлек дәрәҗәсен күтәрү;

спорт объектларының, шул исәптән өлкән яшьтәге затлар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен дә үтемлелеген арттыру.

1 нче ярдәмче программаның бурычлары:

гражданнарның физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивациясен арттыру;

физик культура һәм спорт инфраструктурасын үстерү, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен;

«Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын һәм аны үтәүгә әзерлек системасын популярлаштыру;

һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары базасында студентлар спортын үстерү.

Массакүләм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтенең приоритетлары һәм максатлары соңгы ун елда барлыкка килгән норматив хокукый базада чагылыш тапты. Төп документлар булып Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 ел, 7 август, 1101-б номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә физик культура һәм спортны үстерү стратегиясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 15 апрель, 302 нче карары белән расланган «Физик культура һәм спортны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 ел, 21 гыйнвар, 30 нчы карары белән расланган «2016 – 2020 елларга Россия Федерациясендә физик культура һәм спортны үстерү» федераль максатчан программасы тора. Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел, 5 февраль, 164-б номерлы боерыгы белән 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә өлкән буын гражданнары мәнфәгатьләрендә гамәлләр стратегиясе расланды, анда урта һәм өлкән яшьтәге гражданнарның сәламәтлеген ныгыту өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә зур әһәмият бирелә. Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 24 мартындагы 172 номерлы Указы белән 2014 елның

1 сентябреннән «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы гамәлгә кертелде. Балалар-яшүсмерләр, мәктәп һәм студентлар спортын үстерү, шулай ук Россия Федерациясе спорт җыелма командалары өчен перспектив спортчылар һәм спорт резервы санын арттыру өчен өстәмә хокукый шартлар булдырылган.

1 нче ярдәмче программа кысаларында «Спорт – тормыш нормасы» федераль проекты чаралары, шул исәптән халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре: балалар һәм укучы яшьләр (студентлар), урта һәм өлкән яшь төркемнәре, инвалидлар һәм сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар, шул исәптән инвалид балалар өчен физкультура һәм комплекслы физкультура чаралары гамәлгә ашырылды. Татарстан Республикасы халкы арасында мәгариф системасында, барлык милек рәвешендәге предприятиеләрдә «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын кертү һәм популярлаштыру буенча эш дәвам итте. Студентлар спортын үстерүгә зур игътибар бирелә.

Татарстан Республикасы халкын физик культура һәм массакүләм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатыннан, спорт инфраструктурасын модернизацияләү һәм төрле яшь категорияләре һәм төркемнәре өчен спорт корылмаларының үтемлелеген арттыру буенча эш алып барылды.

Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүчеләр саны, 2016 ел белән чагыштырганда, 15,6 дан 49,5 процентка кадәр, ягъни 34 процентка диярлек арткан. Инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында бу күрсәткеч 2019 ел нәтиҗәләре буенча 28 процент тәшкил итте (исәп-хисап физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә каршы күрсәткечләре булмаган инвалидлар саныннан башкарылган).

2017 – 2019 елларда Татарстан Республикасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау нормативларын (тестларны) үтәү буенча 51 тест үзәге, 258 тест уздыру урыны булдырылды.

Татарстан Республикасының физкультура һәм спорт чараларының бердәм календарь планы нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы ел саен 800дән артык физкультура чарасы уздыра, шул исәптән балалар һәм укучылар арасында да. 2013 елдан 2019 елга кадәр үткәрелә торган чараларның саны 45 процентка диярлек арткан.

Дәүләт адаптив спортны үстерүгә юнәлдерелгән федераль һәм төбәк программаларын төзи, пилот проектларны гамәлгә ашыра. Россия Федерациясенең закон чыгару базасында инвалидлар һәм сәламәтлек хәлендә чикләүләре булмаган кешеләрнең хокукларын тигезли торган документлар барлыкка килә. Әмма хәзерге вакытта хокукларның тигезлеге, нигездә, декларатив характерга ия, аларны гамәлгә ашыру өчен чын шартлар булмау сәбәпле, алар күбесенчә Россия Федерациясе төбәкләрендә, аерым алганда Татарстан Республикасында һәм муниципаль дәрәҗәдә адаптив спорт үсеше белән идарә итү проблемасының фәнни-гамәли эшләнмәләренең җитмәве белән бәйле.

Республикада адаптив физик культура һәм спортны үстерү түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

массакүләм адаптив физик культураны үстерү;

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләү;

югары казанышларның адаптив спортына ярдәм итү.

Татарстан Республикасында 292 786 инвалид яши, алар арасында 15 277 инвалид бала һәм яшүсмер бар.

Инвалидлар һәм сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында 2018 – 2019 елларда 48 гә якын республика массакүләм физкультура чарасы үткәрелде, аларда 2 меңнән артык кеше катнашты. 2016 – 2017 еллар белән чагыштырганда үткәрелә торган чемпионатлар һәм беренчелекләр саны 15 процентка диярлек арткан. Инвалидлар һәм сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спорт корылмаларының өлеше биш ел эчендә 15 процентка диярлек арткан.

Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлеге территориясендә инвалидларны һәм сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затларны адаптив физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү эше алып барыла. Иң күп эш Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә һәм Татарстан Республикасының Азнакай, Саба, Мамадыш, Лаеш муниципаль районнарында алып барыла.

Татарстан Республикасында спорт корылмаларының һәм спорт мәктәпләренең киң челтәре нәтиҗәле эшли, иң югары дәрәҗәдәге бөтенроссия һәм халыкара ярышлар уңышлы уздырыла, киң даирә халык арасында физкультура-сәламәтләндерү эшенең яңа формалары кертелә, спартакиада хәрәкәте үсә.

Федераль программа һәм «Уңайлы мохит» тормыш итүнең уңайлы мохитен булдыру буенча республика ярдәмче программасы кысаларында 2011 елдан башлап республиканың эре шәһәрләрендә 57 спорт объекты тулысынча җайлаштырылган, 2017 елда тагын 7 спорт объекты җайлаштырылган (2011 елда – 82,0 млн.сумга 14 объект, 2014 елда – 62,6 млн. сумга 17 объект, 2015 елда – 20,0 млн. сумга 16 объект, 2016 елда – 9,7 млн. сумга 10 объект).

Инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен адаптив физик культура буенча дәресләр Татарстан Республикасының 142 учреждениесендә, спорт комплексларында оештырыла.

2010 елдан 2019 елга кадәр өч спорт федерациясе булдырылды һәм яңадан аккредитацияләнде:

Татарстан Республикасы Сукырлар спорты федерациясе;

Татарстан Республикасы Терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар категорияләре федерациясе;

Татарстан Республикасы Саңгыраулар спорты федерациясе.

Татарстан Республикасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан аңа беркетелгән төп паралимпия спорт төрләрен үстерә:

кышкы дисциплиналар: биатлон, чаңгы ярышлары (терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар спорты);

җәйге дисциплиналар: коляскадагы бочча, баскетбол (терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар спорты), голбол һәм мини-футбол 5×5 (күрү сәләте бозылган затлар спорты).

Спортның база паралимпия һәм сурдлимпия төрләре буенча Россия Федерациясе җыелма командаларына һәм Татарстан Республикасы җыелма командасына резерв әзерләүне гамәлгә ашыручы терәк оешмалар буларак «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе һәм «Республика спорт-адаптив мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе билгеләнде.

Массакүләм адаптив спортны үстерү буенча эшләрне оештыру Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан «Татарстан Республикасы инвалидларының физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы (алга таба – Татарстан Республикасы инвалидлар ФСҖ) һәм спорт төрләре буенча федерацияләр белән берлектә гамәлгә ашырыла.

2015 елда «Республика спорт-адаптив мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесен булдыру адаптив физик культура һәм спорт үсешенә көчле этәргеч булды. Хәзерге вакытта мәктәптә начар ишетүчеләр (ирекле көрәш, керлинг, йөзү, җиңел атлетика, тхэквондо), терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар (бочча, йөзү, чаңгы ярышлары, җиңел атлетика), интеллектуаль җитешсезлекләр булган затлар (җиңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү), сукырлар (йөзү, җиңел атлетика) спорты эшли.

Эш тәҗрибәсен, кадрлар потенциалын һәм 6-18 яшьлекләр категориясендә инвалид балалар һәм яшүсмерләрнең адаптив спорт төрләрен үстерү өлкәсендә перспективалы составын исәпкә алып, республика мәктәбе базасында икенче этап булып Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендә, шулай ук Татарстан Республикасының Лаеш, Мамадыш һәм Саба муниципаль районнарында бүлекләр ачылды.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә бүлекләрне исәпкә алып, спорт мәктәбендә 241 укучы шөгыльләнә.

Адаптив спортта кадрлар белән тәэмин итү мөһим һәм проблемалы мәсьәлә булып тора. 2019 ел нәтиҗәләре буенча бу күрсәткеч тармакның 2 процентыннан бераз артып киткән (2017 ел – 1,7 процент, 2018 ел – 2,0 процент).

2019 елда адаптив физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрнең кадрлар составын арттыру максатларында «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе базасында «Адаптив физик культура һәм спорт» өстәмә һөнәри программасы буенча белгечләрне һөнәри яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү курслары уздырылды (83 кеше).

Бүгенге көндә республикада сәламәтлек буенча тайпылышлары булган затлар (балалар) саны арту белән бәйле рәвештә физик тернәкләндерү, физик, психик һәм социаль сәламәтлекләрен коррекцияләү таләп ителгән шундый ук эш алып бару зарур.

2019 елда Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы инвалидлар ФСҖ һәм спорт төрләре буенча федерацияләр белән берлектә спорт төрләре буенча ярышлар уздырылды:

Татарстан Республикасының 18 чемпионаты: ирекле көрәш (начар ишетүчеләр спорты), грек-рим көрәше (начар ишетүчеләр спорты), хатын-кызлар көрәше (начар ишетүчеләр спорты), чаңгы ярышлары (барлык категория инвалидлар арасында), футбол (начар ишетүчеләр спорты), хатын-кызлар арасында голбол (сукырлар спорты), өстәл теннисы (төрле категория инвалидлар арасында), өстәл теннисы (сукырлар спорты), бочче (терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган инвалидлар арасында), җиңел атлетика (барлык категория инвалидлар арасында), В1 (тоталь

сукырлар өчен), футбол буенча 12+В3 (начар күрүчеләр һәм калдык күрүче затлар өчен), рус шашкасы, халыкара шашка, шахмат, армспорт;

Татарстан Республикасының 11 беренчелеге: ирекле һәм грек-рим көрәше (начар ишетүчеләр спорты), чаңгыда узышу (барлык категория инвалидлар арасында), кызлар һәм яшүсмерләр арасында голбол (сукырлар спорты), өстәл теннисы (барлык категория инвалидлар арасында), бочче (терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган инвалидлар арасында), В2+В3 футбол (начар күрүчеләр һәм калдык күрүче затлар өчен).

Татарстан Республикасында адаптив спортны үстерү проблемаларына зур игътибар бирү нәтиҗәсендә 2007 елдан 2019 елга кадәр даими рәвештә спорт белән шөгыльләнүче инвалидлар саны 20 тапкырга диярлек арткан.

2019 елда 254 инвалид спортчы Татарстан Республикасы җыелма командасы составына керде, 54 инвалид спортчы Россия җыелма командасы составына кертелде, 300 дән артык инвалид спортчы ел дәвамында тренировкалар чараларына, бөтенроссия һәм халыкара ярышларга командировкалана. Безнең спортчылар Россия, Европа, дөнья чемпионатлары, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары чемпионнары һәм призерлары. 2019 ел белән чагыштырганда, 2013 елда Татарстан Республикасы җыелма командасы составына 136 инвалид спортчы һәм Россия җыелма командасы составына 23 инвалид спортчы кергән.

2019 елгы чараларда, шул исәптән Республика инвалидлар спартакиадасында, республиканың 24 муниципаль берәмлегеннән 2,5 мең кеше катнашты. Халыкара һәм бөтенроссия ярышларында катнашу нәтиҗәләре буенча безнең спортчыларыбыз төрле дәрәҗәдәге 60тан артык медаль яуладылар. Безнең спортчыларыбыз тотрыклы рәвештә Россия, Европа, дөнья, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннарында җиңүчеләр булалар (2018 елгы Паралимпия кышкы уеннарында Татарстан Республикасыннан Россия җыелма командасы составында Россиянең атказанган спорт мастеры Зәйнуллина Марта уңышлы чыгыш ясады. Старт нәтиҗәләре буенча ике спорт төрендә терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар арасында биатлон һәм чаңгы ярышларында ярышучы спортчы көмеш һәм ике бронза медаль яулады).

Гомумән алганда, 25 ел дәвамында Татарстан Республикасы инвалидлар ФСҖ эшләгән чорда җәмгыятьнең тренерлар составы тарафыннан әзерләнде:

7 халыкара класслы спорт мастеры, Россиянең атказанган спорт мастерлары, йөзү буенча Сурдлимпия уеннары чемпионы Федорова Ольга, чаңгыда узышу һәм биатлон буенча Туриндагы Паралимпия уеннары чемпионы Полякова Ирина, пауэрлифтинг буенча Пекин Паралимпиадасының көмеш призеры Закиров Айрат, дөнья һәм Европа чемпионнары, халыкара класслы спорт мастерлары, грек-рим, ирекле көрәш, армспорт, рус шашкалары, чаңгы ярышлары, җиңел атлетика, голбол һәм башка спорт төрләре буенча Россия спорт мастерлары;

Россиянең 38 спорт мастеры (шул исәптән 2016 елда Россиянең 10 спорт мастеры);

спортның төрле төрләре буенча спорт мастерлыгына 54 кандидат.

Татарстан Республикасында адаптив спортны үстерүгә финанс ярдәме күрсәтү, инвалид спортчыларны командировкага җибәрү өчен ел саен 4 млн. сум тирәсе акча бүлеп бирелә.

Инвалид спортчыларга ярдәм итү максатларында, аларның чыгышлары нәтиҗәләре буенча республика бюджетыннан сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән спортчыларга һәм аларның тренерларына спортта югары казанышлар өчен ай саен бирелә торган түләүләр, стипендияләр һәм бердәм вакытлы премияләр бирелә. Хәзерге вакытта 50ләп инвалид спортчыга (2016 елда – 43 инвалид спортчы) ай саен 600 мең сум күләмендә стипендия түләнә. Еллык түләүләр 7 млн. сумнан артык тәшкил итә.

2018 һәм 2019 еллардагы чыгышлар нәтиҗәләре буенча 3 млн. сумга якын премиаль түләүләр түләнгән.

Адаптив физик культура һәм спорт буенча спорт юнәлешендәге учреждениеләргә ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру өлешендә, Россия Федерациясенең 2011 – 2020 елларга «Уңайлы мохит» дәүләт программасы кысаларында, спорт адаптив мәктәбе өчен финанслашу форматында 2019 елда 5,4 млн. сумлык спорт инвентаре һәм җиһазлары сатып алынды.

Физик культура һәм массакүләм спортны тотрыклы үстерү тенденцияләренә карамастан, яшәү урыны буенча халык, инвалидлык, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль дәрәҗәсендә финанс һәм кадрлар белән тәэмин итү, яшәү урыны буенча йорт яны территорияләрен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен зоналар белән тәэмин итү белән бәйле проблемалар бар.

Физик культура һәм спорт тармагын үстерү буенча республика һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру кысаларында, 2023 ел ахырына физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче республика халкының чагыштырма авырлыгын 54,5 процентка кадәр арттыру программаларны гамәлгә ашыруның мөһим нәтиҗәсе булачак.

Физик культура һәм спортның оештырылган формалары белән колачланган Татарстан Республикасы халкы саны

(мең кеше һәм халыкның гомуми санынннан процент)

| 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 000,7<br>26,58% | 1 091,5<br>28,7% | 1 232,8<br>32,25% | 1 330,2<br>37,43% | 1 419,4<br>39,83% | 1 483,7<br>41,51% | 1 556,9<br>43,4% | 1 706,0<br>45,7% | 1787,39<br>49,5% |

2019 елның февралендә Казан шәһәрендә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә «Россия чаңгы юллары – 2019» XXXVII Бөтенроссия массакүләм чаңгы ярышлары һәм «Татарстан чаңгы юллары – 2019» республика массакүләм чаңгы ярышлары үткәрелде. Татарстан Республикасында чаңгы ярышлары стартына 171 950 кеше чыкты.

2019 елның 21 сентябрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә «Татарстан кроссы – 2019» республика массакүләм ярышлары үткәрелде, 2019 елның 6 октябрендә Казан шәһәрендә «Милләтләр кроссы – 2019» Бөтенроссия йөгерү көне узды. Татарстан Республикасында җиңел атлетика ярышлары стартына 232 739 кеше чыкты.

Республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә 2019 елда А.В.Тарасов ис. «Алтын алка» бөтенроссия яшь хоккейчылар клубының традицион ярышлары һәм

футбол буенча «Күн туп» бөтенроссия ярышлары уздырылды. Катнашучыларның гомуми саны 16 меңгә якын.

2019 елда бөтенроссия ярышларында катнашу нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы командалары югары нәтиҗәләр күрсәттеләр.

2019 ел дәвамында Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәткәрләре Спартакиадасы һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре Спартакиадасы кысаларында ярышлар узды.

Дәүләт хезмәткәрләре арасында ярышлар спортның 9 төре буенча үткәрелде, аларда 32 министрлык һәм ведомство хезмәткәрләре катнашты. Дәүләт хезмәткәрләре спартакиадасы нәтиҗәләре буенча урыннар түбәндәгечә бүленде:

1 урын – Татарстан Республикасы Президенты Аппараты командасы;

2 урын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты командасы;

3 урын – Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе командасы.

Муниципаль хезмәткәрләр арасында ярышлар спортның 8 төре буенча үткәрелде, аларда Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегенең башкарма органнары хезмәткәрләре катнашты. Муниципаль хезмәткәрләр Спартакиадасы нәтиҗәләре буенча урыннар түбәндәгечә бүленде:

1 нче төркем:

1 урын – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге командасы;

2 урын – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы командасы;

3 урын – Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы командасы;

2 нче төркем:

1 урын – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы командасы;

2 урын – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы командасы;

3 урын – Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы командасы;

3 нче төркем:

1 урын – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы командасы;

2 урын – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы командасы;

3 урын – Татарстан Республикасының Чүпрәле муниципаль районы командасы.

2018 елда Татарстан Республикасында TIMERMAN спорт чараларының комплекслы программасын булдыру инициативасы тормышка ашырылды, ул үз эченә түбәндәге спорт төрләре буенча ярышлар ала: чаңгы ярышлары, җиңел атлетика узышлары, йөзү, велосипед спорты һәм триатлон. Стартларда профессиональ спортчылар да, һәвәскәрләр дә катнаша. 2019 елда Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Яшел Үзән шәһәрләрендә, Свияжск утрау-шәһәрлегендә һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында 19 чара уздырылды, аларда дөньяның 800дән артык торак пунктыннан 50 меңнән артык спортчы һәм һәвәскәрләр катнашты:

26 гыйнвар –Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында төнге чаңгы ярышы (420 кеше);

1 февраль – Әлмәт шәһәрендә Snow Fest фестивале (850 кеше);

17 февраль – Чаллы шәһәрендә Кама чаңгы марафоны (550 кеше);

17 март – Яшел Үзән чаңгы марафоны (550 кеше);

5 май – Казан марафоны (25 мең кеше);

19 май – «Идел буйлап йөгерү» ярыммарафоны (2 500 кеше);
19 июнь – «Тур де Татарстан Әлмәт» велоузышы (550 кеше);
16 июнь – Яшел Үзән трейлы (1 500 кеше);
23 июнь – Әлмәт триатлон (320 кеше);
30 июнь – «Тур де Татарстан» велоузышы (1 050 кеше);
6 июль – Зөя утрау-шәһәре тирәсендә Sviyaga Swim ачык суда йөзү (510 кеше);
14 июль – Түбән Кама триатлон (250 кеше);
20 июль – «Төнге Казан» йөгереше (2 800 кеше);
29 июль – Timerman&Ironstar триатлон (1 800 кеше);
4 август – Чаллы шәһәрендә Kama Swim ачык суда йөзү (220 кеше);
11 август – Чаллы шәһәрендә Кама ярыммарафоны (250 кеше);
31 август – Timerman Kazan Triathlon Full (650 кеше);
7 сентябрь – Әлмәт ярыммарафоны (1 250 кеше);
6 октябрь – Казан ярыммарафоны (8 200 кеше).

2019 елда Россиянең 63 шәһәрендә, шулай ук Искешәһәр (Төркия) шәһәрен дә кертеп, «Яшел фитнес» социаль-спорт проекты эшли башлады, анда 150 меңнән артык кеше колачланган. Татарстан Республикасында проект Казан, Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Бөгелмә, Лениногорск, Баулы, Минзәлә, Менделеевск, Әгерҗе һәм Буа шәһәрләрендә тормышка ашырыла.

2019 елда проект Eventiada IPRA Golden World Awards 2019 халыкара премиясендә «Сәламәт яшәү рәвешен алга этәрүнең иң яхшы проекты» номинациясендә 2 нче урынны алды, Татарстан Республикасының ел саен үткәрелә торган «Ел спортчысы» спорт премиясенең «Ел спортчысы» номинациясендә лауреат булды.

2019 ел «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә ашыру кысаларында массакүләм чараларга бай булды. 2019 елда Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, төбәк операторы – Татарстан Республикасының «Хезмәткә һәм оборонага әзер» төбәк иҗтимагый оешмасы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма хакимияте органнары ярдәме белән 710 нан артык чара үткәрелгән, хәрәкәттә катнашучылар саны 135 меңнән артык кеше тәшкил иткән.

Республика башкаласы Казан шәһәрендә һәм муниципаль районнарда «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы хәрәкәтенә предприятиеләр һәм оешмаларның хезмәт коллективлары актив кушылды, күбесе комплекс нормативларын үтәү буенча сессияләрне һөнәри бәйрәмнәргә, шулай ук Сабантуй һәм Татарстан Республикасы көне кебек бәйрәмнәргә багышлаган иде.

2019 елда «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы хәрәкәтендә катнашучылар саны республикада 81 меңнән артык кешегә артты – бу 2018 елның абсолют күрсәткечләре буенча 16 процентка артым. 2019 ел ахырына Татарстан Республикасында 51 тест үткәрү үзәге, шулай ук 358 тест үткәрү урыны эшли. Төбәк операторы тарафыннан граждан-хокукый килешүләр буенча эшләүче белгечләр өчен 88 ставка бүлеп бирелгән.

Иң яшь катнашучылар арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын пропагандалауга юнәлтелгән чараларны

аерым билгеләп үтәргә кирәк. Шулай итеп, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының тест үзәге инициативасы белән 2019 елда өченче тапкыр «Яшь ХОӘшкалар» ачык фестивале оештырылды, анда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр – «Хезмәткә һәм оборонага әзер» комплексының 6 яшьтән алып башлангыч баскыч вәкилләре һәм аларның әти-әниләре катнашты. Бу вакыйга «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы эчендә яңа хәрәкәткә башлангыч бирде. «Яшь ХОӘшкалар» фестивале күңелле гаилә бәйрәме генә түгел, ә «Хезмәткә һәм оборонага әзер» комплексы чараларының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә бөтен җирдә кирәкле нәтиҗәле, аңлаешлы яңа форматына әверелде.

Якты вакыйгалар арасында шулай ук Казан шәһәре мәктәпләренең өлкән сыйныф укучылары арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» фестивален дә билгеләп үтәргә мөмкин, ул беренче ике көндә 2 500 булачак абитуриентны колачлады.

«Милләтләр кроссы» һәм «Россия чаңгы юллары» кебек йөгерешләрнең стартына һәрвакыт күп кеше килүе «Хезмәткә һәм оборонага әзер» комплексының мәҗбүри нормативларын массакүләм үтәү исәбенә үткәрергә мөмкинлек бирде.

«ХОӘ билеты» акциясе кысаларында «Ак Барс» хоккей клубы һәм «Уникс» баскетбол клубының өй матчларында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» мәйданчыгы эшләде, анда барлык теләүчеләр комплекс белән таныша һәм үз көчләрен сынап карый алдылар. Тестларны уңышлы узучылар призлар һәм командаларның киләсе матчларына бушлай билетлар алдылар. Шул ук акция кысаларында махсус фестиваль барышында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» комплексы нормативларын уңышлы үтәгән Казан шәһәренең коррекция мәктәпләре укучылары матчларга 100 дән артык билет алды.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының «Буревестник» яшьләр физкультура-спорт җәмгыяте» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы белән берлектә, 2019 елда Татарстан Республикасы югары уку йортлары арасында 2018/2019 уку елында барлыгы 2 039 кеше катнашкан спартакиада үткәрде, шул исәптән спортның түбәндәге 15 төре буенча 28 ярыш үткәрелде: чаңгы ярышлары, бадминтон, фитнес-аэробика, билбау көрәше, чаңгыларда спорт ориентлашуы, дзюдо, өстәл теннисы, спорт көрәше, хатын-кызлар һәм ир-атлар арасында мини-футбол, бөтен стильдәге каратэ, җиңел атлетика, беренче май эстафетасы, бокс, авыр атлетика.

2018/2019 уку елында Татарстан Республикасы югары уку йортлары Спартакиадасы ярышлары нәтиҗәләре буенча урыннар түбәндәгечә бүленде:

1 нче төркем:

абсолют чемпион – «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (34 спорт төрендә катнашкан, 24 спорт төрендә беренче урыннарны алган, спорт лигаларында гомуми приз фонды 1,09 млн. сум тәшкил итә.);

1 урын – «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (спортның 31 төрендә катнашкан, 7 төрендә беренче урыннарны алган);

2 урын – «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (спортның 35 төрендә катнашкан, 4 төрендә беренче урыннарны алган);

3 урын – «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (программаның 33 төрендә катнашты);

2 нче төркем:

1 урын – «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (27 спорт төрендә катнашты, 11 төрдә беренче урыннарны яулады);

2 урын – «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты» югары белем бирү шәхси мәгариф учреждениесе (спортның 20 төрендә катнашкан, 6 төрдә беренче урыннарны алган);

3 урын – «Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (спортның 28 төрендә катнашкан, 4 төрендә беренче урыннарны алган).

2019 елның I кварталында спорт төрләре буенча студентлар спорт лигасы ярышларының икенче турына старт бирелде, анда 4 989 студент-спортчы катнашты. Сезон өчен ярышларның гомуми саны – 57, шул исәптән ярышлар:

ирләр командалары арасында Татарстан Республикасы Студентлар футбол лигасы (ТР СФЛ). 14 югары белем бирү оешмасыннан һәм 11 һөнәри белем бирү оешмасыннан 625 кеше катнашкан 134 уен үткәрелде;

ирләр командалары арасында Татарстан Республикасы Студентлар хоккей лигасы (ТР СХЛ). 67 уен үткәрелде, аларда 11 югары белем бирү оешмасыннан һәм 22 һөнәри белем бирү оешмасыннан гомуми санда 663 кеше катнашты;

ирләр командалары арасында Татарстан Республикасы Студентлар волейбол лигасы (ТР СВЛ). 18 югары белем бирү оешмасыннан һәм 23 һөнәри белем бирү оешмасыннан 876 кеше катнашкан 110 уен үткәрелде;

ирләр командалары арасында Татарстан Республикасы Студентлар баскетбол лигасы (ТР СБЛ). 21 югары белем бирү оешмасыннан һәм 28 һөнәри белем бирү оешмасыннан 818 кеше катнашкан 166 уен үткәрелде;

хатын-кызлар командалары арасында Татарстан Республикасы Студентлар баскетбол лигасы (ТР СБЛ). 20 югары белем бирү оешмасыннан һәм 28 һөнәри белем бирү оешмасыннан 627 кеше катнашкан 142 уен үткәрелде;

ирләр командалары арасында Татарстан Республикасы Студентлар гандбол лигасы (ТР СГК). 9 югары белем бирү оешмасыннан һәм 4 һөнәри белем бирү оешмасыннан 214 кеше катнашкан 40 уен үткәрелде;

ир-атлар һәм хатын-кызлар командалары арасында Татарстан Республикасы Студентлар регби (регби-7) лигасы (ТР СГЛ). Барлыгы 60 уен (ир-атлар командалары арасында 41 уен, хатын-кызлар командалары арасында 19 уен) уздырылды, анда гомуми саны 195 кеше, 13 команда (8 ир-ат командасы, 5 хатын-кыз командасы), 8 югары белем бирү оешмасыннан 8 команда катнашты;

ир-атлар һәм хатын-кызлар командалары арасында Татарстан Республикасы Студентлар пейнтбол лигасы (ТР СПЛ). 62 уен үткәрелде, 10 югары белем бирү оешмалары командаларыннан гомуми катнашучылар саны 103 кеше.

Татарстан Республикасы «Сәламәт яшәү рәвеше өчен – 2019! Кышкы каникуллар!» декадасы кышкы каникуллар вакытында югары белем бирү оешмалары фәнни-педагогик хезмәткәрләре һәм хезмәткәрләре арасында сәламәтлекне ныгыту, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, спорт хәрәкәтен саклау, үстерү, югары уку йортлары арасында мөнәсәбәтләрне үстерү, студент-спортчыларны әзерләгәндә тәҗрибә уртаклашу максаты белән үткәрелә.

Татарстан Республикасы «Сәламәт яшәү рәвеше өчен – 2019! Кышкы каникуллар!» декадасы кысаларында барлыгы спортның 6 төре буенча 7 ярыш үткәрелде, аларда 13 югары белем бирү оешмасыннан 350 кеше катнашты.

Бию спорты буенча Россия Чемпионаты һәм беренчелеге. 2019 елгы спорт сезоны тарихта беренче тапкыр брейкинг буенча Россия чемпионаты һәм беренчелеге ачылды, ул 28 февраль – 1 мартта Казанда узды.

Ике көн дәвамында Гимнастика үзәгендә узган ярышларда Россия Федерациясенең 22 төбәгеннән 37 шәһәрдән килгән 87 клубтан 300 дән артык спортчы катнашты.

2019 елның 2 мартыннан 3 мартына кадәр Казанда бию спорты буенча Россия чемпионаты һәм беренчелеге (Европа һәм Латин Америкасы программалары) узды, анда Россия Федерациясенең 59 төбәгендәге 119 шәһәреннән 300 бию-спорт клубыннан 1000гә якын бию дуэты катнашты. Бию спорты буенча ярышларда катнашучыларның гомуми саны 3 300 кеше тәшкил итте.

Татарстан Республикасының «Буревестник» яшьләр физкультура-спорт җәмгыяте» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы эшчәнлегенең аерылгысыз өлеше булып студент-спортчыларны эре халыкара ярышларга әзерләү тора:

Красноярск шәһәрендә Бөтендөнья кышкы Универсиада. Россия җыелма командасы составына Татарстаннан 25 кеше керде, алар чаңгы ярышлары, сноуборд, фигуралы шуу, алкалы хоккей һәм туплы хоккей буенча чыгыш ясадылар. Шуларның 23е – Казан югары уку йортлары студенты;

Неаполь шәһәрендә (Италия) Бөтендөнья җәйге Универсиада. Россия җыелма командасы составына Татарстаннан 19 кеше керде, алар спортның 9 төрендә: суга сикерү, тхэквондо, баскетбол, су полосы, өстәл теннисы, волейбол, зур теннис, стендка ату һәм йөзү буенча чыгыш ясады. Татарстан вәкилләре активында 14 медаль бар: 2 алтын, 4 көмеш һәм 8 бронза.

Гомумән алганда, 2018/2019 уку елында студентлар спорты линиясе буенча 115 ярыш үткәрелгән. Катнашучыларның гомуми саны 8 635 кеше тәшкил итте (профессорлар-укытучылар составы ярышларын исәпкә алып).

2019 елның 4 – 10 октябрендә Казан шәһәрендә Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегендә катнашучы дәүләтләр арасында мәктәп спортының VII Халыкара фестивале узды. Фестивальдә катнашучылар түбәндәге спорт төрләрендә иң көчлеләрне билгеләделәр: мини-футбол, баскетбол, волейбол, баскетбол 3×3, өстәл теннисы, бадминтон, шахмат һәм мини су полосы.

Фестивальдә 11 илдән: Әзербайҗан Республикасы, Әрмәнстан Республикасы, Беларусь Республикасы, Казахстан Республикасы, Кыргызстан Республикасы, Молдова Республикасы, Россия Федерациясе, Таҗикстан Республикасы, Төркмәнстан, Украина, Үзбәкстан Республикасы җыелма командалары составында 500ләп спортчы катнашты.

Түбәндәге югары белем бирү мәгариф оешмаларында студентлар спорт клублары актив үсеш ала: "Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе – «Казан юлбарыслары», «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе – «Академия», «А.Н.Туполев ис. Казан милли тикшеренү техник университеты– КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе – «КАИ-Зилант». Югарыда аталган клублар рәсми рәвештә Россия студентлар спорт клублары ассоциациясе реестрында теркәлгән. Әлеге клуб вәкилләре даими рәвештә төбәк, бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге студентлар ярышларында катнашу өчен командалар куя.

2019 елның 29 маеннан 2 июненә кадәр Казан шәһәрендә «Безнең сайлау – спорт!» Россия студентлар спорт клублары ассоциациясе фестивале узды. Югары дивизионның Алтын Кубогы Татарстанда калды: «Казан юлбарыслары» студентлар спорт клубы җиңүче дип игълан ителде. Шул ук дивизионда «Академия» командасы өченче урынны алды.

«КАИ-Зилант» студентлар спорт клубы 2019 елда студентлар спорты өлкәсендә «Тормыш формуласы» бөтенроссия ихтыярый ярдәмчеләр фестивалендә иң яхшысы булды.

«Спартак-Татарстан» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе һәм республиканың тармак һөнәр берлекләре федерациясе ярдәме белән 2019 елда 18 яшь һәм аннан да өлкәнрәк 7 523 кешене физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм чараларда катнашу өчен җәлеп итә алды. 2019 елда җәмгыять тарафыннан барлыгы 50 дән артык спорт юнәлешендәге чара үткәрелгән. Ярышларда физик культура буенча 250дән артык хезмәт коллективы катнашты. Ел дәвамында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең спорт объектларында барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр хезмәткәрләре арасында «Сәламәтлек-2019» Спартакиадасы уздырылды. Спартакиада традиция буенча өч этапта үткәрелә: беренче этап – предприятиеләр һәм оешмалар эчендә, икенче этап – тармак предприятиеләре һәм оешмалары арасында, өченче этап – тармакара финал ярышлары.

Спартакиада программасында – чаңгы ярышлары, пуля белән ату, өстәл теннисы, волейбол, мини-футбол, җиңел атлетика, шахмат, шашка, дартс, стритбол буенча ярышлар.

2019 елгы Спартакиада нәтиҗәләре буенча призлы урыннарны түбәндәге спорт командалары алды:

1 урын – сәнәгатьнең химия тармагы хезмәткәрләре һөнәри берлегенең Татарстан республика оешмасы;

2 урын – «Татарстан Республикасы автомобиль транспорты һәм юл хуҗалыгы хезмәткәрләренең һөнәри берлеге» иҗтимагый оешмасы;

3 урын – Россия авиация сәнәгате хезмәткәрләре һөнәри берлегенең Татарстан республика оешмасы.

Балалар һәм яшүсмерләр катнашында яңа юнәлешләргә дә зур игътибар бирелә. 2019 елның мартында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Кавал авылының «Дружба» спорт-ял итү үзәгендә нәфис гимнастика буенча

«Спартак-Татарстан» физкультура-спорт җәмгыяте бүлекчәсенең Mickey Mouse Cup ачык республика турниры үткәрелде. Турнирда Мәскәү, Йошкар-Ола, Чабаксар, Казан, Зеленодольск, Биектау районнары командалары катнашты. Анда 8 яшь төркеме буенча 323 гимнастка (2007 – 2014 елларда туган) катнашты.

Балаларны һәм яшүсмерләрне физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатыннан Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы республиканың муниципаль берәмлекләре белән берлектә яшәү урыны буенча эш алып бара.

Ел дәвамында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән берлектә футбол буенча «Күн туп» һәм хоккей буенча «Алтын алка» бөтенроссия массакүләм ярышлары оештырыла. Әлеге ярышларда катнашучы балалар һәм яшүсмерләр саны 16 меңгә якын кеше тәшкил итә.

Республикада балалар һәм яшүсмерләр өчен спортның техник төрләрен үстерүгә – картингка зур игътибар бирелә. Ел дәвамында Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогының «Маяк» һәм Лесхоз бистәсенең «Аргамак» (Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы), «Камаз» (Чаллы шәһәре) картодромнарында, «Форсаж» картинг-үзәгендә (Казан шәһәре) картинг буенча бөтенроссия һәм республика ярышлары үткәрелә. Катнашучылар саны ел саен 3 меңгә якын кеше тәшкил итә (узышчылар һәм хезмәт күрсәтүче персонал – техниклар).

Ел саен 1 июньдә республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә төрле категория балалар һәм яшүсмерләр катнашында Балаларны яклау көненә багышланган спорт-массакүләм чаралар һәм мәдәни-спорт бәйрәмнәре үткәрелә. Ел саен август аенда республикада Физкультурачылар көненә багышланган спорт чаралары үткәрелә.

2019 елда Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының календарь планы нигезендә «Татарстан Республикасының «Уңыш» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы тарафыннан Татарстан Республикасының авыл җирлекләре арасында XVI «Сәламәтлек» авыл Спартакиадасы уздырылды. Спартакиада программасына спортның 13 төре буенча ярышлар керде: чаңгы ярышлары, волейбол, ир-атлар һәм хатын-кызлар командалары арасында, армрестлинг, шашка, җиңел атлетика, ир-атлар командалары арасында мини-лапта, ир-атлар командалары арасында мини-футбол, җәяүлеләр дистанцияләрендә спорт туризмы, ир-атлар һәм хатын-кызлар командалары арасында бадминтон, баскетбол, шахмат, өстәл теннисы, шулай ук авыл җирлекләренең спорт гаиләләре республика ярышлары.

Спартакиаданың спорт төрләре буенча ярышлар республиканың аерым чемпионатлары рәвешендә ике этапта үткәрелә: беренче этап – республика районнары авыл җирлекләре предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре коллективлары командалары арасында спорт төрләре буенча ярышлар; икенче этап – финал ярышлары – Спартакиада программасына кертелгән спорт төрләре буенча чемпионатлар.

Финал ярышларында Татарстан Республикасының 43 муниципаль районы командалары катнаша. Спорт төрләре буенча финал ярышларында катнашучыларның гомуми саны якынча 2 мең кеше тәшкил итә.

Татарстан Республикасы «Сәламәтлек» XVI авыл Спартакиадасы гомумкоманда зачетында җиңүче һәм призерлар ике төркем буенча билгеләнде:

республика әһәмиятендәге шәһәрләргә карамаган муниципаль районнар:

1 урын – Саба муниципаль районы;

2 урын – Спас муниципаль районы;

3 урын – Арча муниципаль районы;

республика әһәмиятендәге шәһәрләргә караган муниципаль районнар:

1 урын – Түбән Кама муниципаль районы;

2 урын – Зәй муниципаль районы;

3 урын – Азнакай муниципаль районы.

2020 елның 19 – 23 мартында Төмән өлкәсенең Төмән шәһәрендә IX Бөтенроссия кышкы авыл спорт уеннары узды.

Татарстан Республикасының спорт делегациясе уеннар программасының 2 төрендә (полиатлон, механизаторлар ярышлары) 4 спортчы, 1 тренер, 1 җитәкче (барлыгы 6 кеше) йөзендә республиканың 2 муниципаль районы – Актаныш һәм Балтач авыл җирлекләреннән тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы җыелма командасы гомумкоманда зачетында 800 мең һәм аннан да күбрәк авыл халкы булган төркем буенча 4 нче урынны алды.

2019 елның 10 – 15 сентябрендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актаныш авылында Татарстан Республикасының «Авыл яшьләре» XI җәйге авыл спорт уеннары узды.

Ярышларда Татарстан Республикасының 43 муниципаль районыннан командалар катнашты, аларның гомуми саны 1 275 кеше иде. Уеннар спортның 11 төре буенча үткәрелде: мас-рестлинг (таяк тартышу), көрәш, аркан тарту, җиңел атлетика, волейбол, өстәл теннисы, шашка, шахмат, бадминтон. Уеннар программасына шулай ук профильле ярышлар – сыер савучылар һәм механизаторлар ярышлары да кертелгән.

Авыл уеннарының гомумкоманда зачеты ике төркем буенча үткәрелде:

республика әһәмиятендәге шәһәрләргә карамаган муниципаль районнар (1 төркем):

1 урын – Саба муниципаль районы;

2 урын – Мамадыш муниципаль районы;

3 урын – Актаныш муниципаль районы;

республика әһәмиятендәге шәһәрләргә караган муниципаль районнар (2 төркем):

1 урын – Буа муниципаль районы;

2 урын – Зәй муниципаль районы;

3 урын – Азнакай муниципаль районы.

2019 елның 24 – 26 октябрендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы призына авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәрләре көненә багышланган XXIV шәхси-команда республика ярышлары уздырылды.

Ярышларда 50 команда катнашты. Катнашучыларның гомуми саны 350 кеше тәшкил итте. Призлы урыннарны түбәндәге командалар яулады:

1 урын – Теләче муниципаль районы;
2 урын – Балтач муниципаль районы;
3 урын – Кукмара муниципаль районы.

### II. 1 нче ярдәмче программаның төп максаты һәм бурычлары, программа чаралары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирнамәсе, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

1 нче ярдәмче программаның максаты булып Татарстан Республикасы халкының физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивациясен арттыру буенча чаралар үткәрү тора.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Татарстан Республикасы халкының төрле категорияләренә һәм төркемнәренә (шул исәптән алар арасында инвалидлыгы булган затлар категорияләре, авыл территорияләрендә яшәүчеләр, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр хезмәткәрләре һ.б. булган) физик тәрбия бирү системасын камилләштерү.

2. Массакүләм спорт өчен, шул исәптән инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен уңайлы спорт инфраструктурасын тәэмин итү.

3. «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) бөтенроссия физкультура-спорт комплексын һәм аны үтәүгә әзерләнү системасын популярлаштыру.

4. Һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары базасында студентлар спортын үстерү.

Куелган максатның масштаблылыгы чаралар комплексын эшләүне таләп итә.

1 нче ярдәмче программа сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, барлык яшьтәге халык төркемнәренең физик активлыгын һәм әзерлеген арттыруга, тулы кыйммәтле итеп ял итү һәм буш вакытны сәламәт итеп үткәрү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны башкаруны күздә тота.

Әлеге чараларны тормышка ашыру халыкның сәламәтлеген ныгыту өчен шартлар тудырырга, республикада демографик хәлне яхшыртырга, массакүләм спортны үстерергә һәм популярлаштырырга, алга таба Татарстанның спорт имиджын халыкара дәрәҗәдә ныгыту максатларында, җәмгыятьнең төрле катламнарын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

1 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2023 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

халыкның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче Татарстан Республикасы халкы өлешен 54,5 процентка кадәр;

«Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын бирүдә катнашкан халыкның гомуми санында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәгән Татарстан Республикасы халкы өлешен 52,0 процентка кадәр:

шулардан белем алучыларның һәм студентларның өлешен 65,0 процентка кадәр;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче

бу категориядәге халык өлешен 29,0 процентка кадәр;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм 6 яшьтән 18 яшькә кадәр инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче бу категориядәге халык өлешен 75,0 процентка кадәр;

Татарстан Республикасы халкының гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче авыл халкы өлешен 34,6 процентка кадәр;

3 – 29 яшь категориясендәге балалар һәм яшьләрнең гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр өлешен 88,0 процентка кадәр;

урта яшьтәге гражданнарның (30 – 54 яшьтәге хатын-кызлар өчен һәм 30 – 59 яшьтәге ир-атлар өчен) гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче урта яшьтәге гражданнар өлешен 48,6 процентка кадәр;

өлкән яшьтәге гражданнарның (55 яшь – 79 яшьтәге хатын-кызлар өчен һәм 60 – 79 яшь яшьтәге ир-атлар өчен) гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче өлкән яшьтәге гражданнар өлешен 24,7 процентка кадәр.

1 нче ярдәмче программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 1 нче ярдәмче программа чаралары буенча финанслау аңа теркәлгән кушымтада китерелә.

1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыруның гомуми вакыты: 2019 – 2023 еллар.

### III. 1 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 156 651,4 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 973 896,6 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 318 916,6 мең сум;
2020 елда – 163 745,0 мең сум;
2021 елда – 163 745,0 мең сум;
2022 елда – 163 745,0мең сум;
2023 елда – 163 745,0мең сум.

Федераль бюджет акчасы исәбеннән күздә тотылган финанслау 182 754,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2019 елда – 69 341,1 мең сум;
2020 елда – 48 299,0 мең сум;
2021 елда – 14 997,3 мең сум;
2022 елда – 25 058,7 мең сум;
2023 елда – 25 058,7 мең сум.

1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

1 нче ярдәмче программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү» (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

2 нче ярдәмче программа исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«2 нче ярдәмче программаның дәүләт заказчылары» юлында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

«2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 13 282 065,8 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 13 207 398,8 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 2 086 737,9 мең сум;<br>2020 елда – 2 750 745,7 мең сум;<br>2021 елда – 2 745 683,2 мең сум;<br>2022 елда – 2 812 116,0 мең сум;<br>2023 елда – 2 812 116,0 мең сум.<br>Федераль бюджет акчасы исәбеннән күздә тотылган финанслау 74 667,0 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 0,0 мең сум;<br>2020 елда – 18 370,0 мең сум;<br>2021 елда – 18 370,0 мең сум;<br>2022 елда – 18 963,5 мең сум;<br>2023 елда – 18 963,5 мең сум<br>2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«2 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «2 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2023 елга түбәндәгеләргә ирешү күздә тотыла:<br>Россия Федерациясенең спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлегенә кертелгән спортчылар санын 577 кешегә кадәр;<br>физик культура һәм спорт өлкәсендәге оешмаларның гомуми санында федераль спорт әзерлеге стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча хезмәт күрсәтүче (шул исәптән физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен) оешмалар өлешен 100 процентка кадәр;<br>спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт буенча камилләшү этабында шөгыльләнүчеләрнең гомуми санында спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда югары спорт осталыгы этабында шөгыльләнүчеләр өлешен 25 процентка кадәр»; |

2 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 2 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 13 282 065,8 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 13 207 398,8 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 2 086 737,9 мең сум;
2020 елда – 2 750 745,7 мең сум;
2021 елда – 2 745 683,2 мең сум;
2022 елда – 2 812 116,0 мең сум;
2023 елда – 2 812 116,0 мең сум.

Федераль бюджет акчасы исәбеннән күздә тотылган финанслау 74 667,0 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 0,0 мең сум;
2020 елда – 18 370,0 мең сум;
2021 елда – 18 370,0 мең сум;
2022 елда – 18 963,5 мең сум;
2023 елда – 18 963,5 мең сум.

2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле финанас елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

2 нче ярдәмче программага теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен

камилләштерү» ярдәмче программасында (алга таба – 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программа исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

3 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«3 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 3 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 224 535,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2019 елда – 61 802,1 мең сум;<br>2020 елда – 38 981,5 мең сум;<br>2021 елда – 40 308,0 мең сум;<br>2022 елда – 41 721,7 мең сум;<br>2023 елда – 41 721,7 мең сум.<br>3 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«3 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «3 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 3 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 20232 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Үз вакытында үтәлмәгән» статусы бирелгән хәбәрнамәләр өлешен 0 берәмлеккә кадәр;<br>Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары йөкләмәләренең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан әлеге затлар тарафыннан үтәлү вакыты билгеләнгән тикшерү вакытларында үтәлгән әлеге йөкләмәләр өлешен 100 процентка кадәр; |

| | |
|---|---|
| | Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, боерыкларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында, боерыкларында бирелгән шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең гомуми санында Татарстан Республикасының әлеге норматив хокукый актларында бирелгән шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан үтәлү өлешен 100 процентка кадәр»; |

3 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге унберенче абзацта «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

3 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 3 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

3 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 224 535,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2019 елда – 61 802,1 мең сум;

2020 елда – 38 981,5 мең сум;

2021 елда – 40 308,0 мең сум;

2022 елда – 41 721,7 мең сум;

2023 елда – 41 721,7 мең сум.

3 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

3 нче ярдәмче программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 4 нче ярдәмче программа):

4 нче ярдәмче программаның исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

4 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td>«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td><td>4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме 18 618 154,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән күздә тотылган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 2 102 313,5 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 16 170 640,9 мең сум, билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган бюджеттан тыш чыганаклар акчасы – 345 200,0 мең сум.<br>(мең сум)
<table>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td rowspan="2">4 нче ярдәмче программа буенча барлык акча</td><td colspan="3">Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>федераль бюджет</td><td>бюджеттан тыш чыганаклар</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>2 282 574,9</td><td>1 950 269,3</td><td>332 305,6</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>6 185 512,5</td><td>4 587 449,9</td><td>1 252 862,6</td><td>345 200,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>4 830 678,3</td><td>4 534 712,1</td><td>295 966,2</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>2 770 283,9</td><td>2 549 104,8</td><td>221 179,1</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>2 549 104,8</td><td>2 549 104,8</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>18 618 154,4</td><td>16 170 640,9</td><td>2 102 313,5</td><td>345 200,0</td></tr>
</table>
4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;</td></tr>
</table>

«4 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td>«4 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге</td><td>4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2023 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>100 мең кешегә исәпләгән спорт корылмалары санын 310 берәмлеккә кадәр;<br>спорт билгеләнешендәге объектларының берьюлы хезмәт күрсәтү сәләтен 67,9 процентка кадәр;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен электр энергиясенең чагыштырма чыгымы (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – 1 кв.метрга 65,67 кВт × сәгать;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен җылылык энергиясенең чагыштырма чыгымы (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга 0,1340 Гкал;</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| редакциядә бәян итәргә: | спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен салкын суның чагыштырма чыгымы (1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) исәпләгәндә) – 1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) 0,1762 куб.метр;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен табигый газның чагыштырма чыгымы (газ белән җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә) – газ белән җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга 29,49 куб.метр;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының ведомство буйсынуындагы мәҗбүри энергетика тикшерүен үткән учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча) өлешен 100 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының ведомство буйсынуындагы исәпкә алу приборлары белән җиһазландырылган учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча) өлешен 100 процентка кадәр»; |

4 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге егерме тугызынчы абзацында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2023» саннарына алмаштырырга;

4 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 4 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме 18 618 154,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән күздә тотылган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 2 102 313,5 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 16 170 640,9 мең сум, билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган бюджеттан тыш чыганаклар акчасы – 345 200,0 мең сум.

(мең сум)

| Ел | 4 нче ярдәмче программа буенча барлык акча | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2019 | 2 282 574,9 | 1 950 269,3 | 332 305,6 | 0,0 |
| 2020 | 6 185 512,5 | 4 587 449,9 | 1 252 862,6 | 345 200,0 |
| 2021 | 4 830 678,3 | 4 534 712,1 | 295 966,2 | 0,0 |
| 2022 | 2 770 283,9 | 2 549 104,8 | 221 179,1 | 0,0 |
| 2023 | 2 549 104,8 | 2 549 104,8 | 0,0 | 0,0 |
| Барлыгы | 18 618 154,4 | 16 170 640,9 | 2 102 313,5 | 345 200,0 |

4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;

4 нче ярдәмче программага теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итәргә;

Программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин